ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ДЕКАБРЬ, 2015 нче ел

№3 (20)

ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!






**1— СПИДка каршы көрәш көне.**

**3 - Халыкара инвалидлар көне**

## Бу санда:


| | |
|---|---|
| Халыкара инвалидлар көне | 2 |
| Ватан геройлары көне | 3 |
| Якынннан танышыйк! | 4 |
| Иң көчлеләр билгеле | 5 |
| Көлке хикмәте | 6 |
| Анкета | 6 |
| Котлыйбыз! | 7 |


## «БЕР ЯЛГЫШ АДЫМ ҺӘМ... БЕР ГОМЕР»

Ел саен **1 декабрь көнне СПИДка каршы Бөтендөнья көрәш көне** билгеләп үтелә. Ул планета төбәкләре буенча таралуын дәвам итүче ВИЧ-инфекциягә каршы көрәшне ныгытуга хезмәт итә. Эпидемия башыннан 30 ел эчендә СПИД 25 миллионнан артык гомерне алып киткән, 60 миллионнан артык кеше ВИЧ белән йогышланган, 16 миллион бала ата-анасыз калган. Әлегә кадәр бу вирусны көн саен 7 меңнән артык кеше йоктыра…

Бүгенге көндә Татарстанның СПИД үзәгендә ВИЧ-инфекция диагнозы белән 18 мең 612 кеше исәптә тора. Республикада әлеге чирнең таралышы 100 мең халыкка 301,6 очрак тәшкил итә. Россиядә исә бу күрсәткеч 498,2 дәрәҗәсендә. Барлыгы ВИЧ-инфекцияле әниләрдән республикабызда 2 450 бала туган, шуларның 95енә ВИЧ-инфекция диагнозы куелган.

**Гөлшат Гайсина**

### Авыру турында

Әйләнештәге канга эләккән ВИЧ вирусы үзен башка авыру кузгатучылар һәм башка ят матдәләр шикелле белгертә. Ул 6-8 атна үткәч кенә тикшерүнең аерым тестлары ярдәмендә ачыкланырга мөмкин.



**Авыру йоктырганнан соң нинди үзгәрешләр була? СПИД ничек уза?**
СПИД белән авыру акрынлап, сизелер-сизелмәс башлана.

Лимфа төеннәре зурая;
Иммунологик дефицит килеп туа: кешене гомуми хәлсезлек билэп ала. Аның кәефе китә, эш сәләте кими, организмы ябыга, сулыш алу, ашкайнату юлларында, тиредә төрле ялкынсыну процесслары күзәтелә.

# 3 декабрь - Халыкара инвалидлар көне

1992 нче елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы Генераль Ассамблеясы Инвалидлар унъеллыгы азагында 3 декабрьне Халыкара инвалидлар көне дип игълан итте. Аталган унъеллык, инвалидларның хәлен яхшырту һәм алар өчен тигез мөмкинлекләр тәэмин итү максатларында, чаралар кабул итү һәм хәбәрдарлыкны арттыру чоры булган. Соңрак БМО Генераль Ассамблеясы БМО әгъза-илләрен Инвалидлар көне уңаеннан чаралар үткәрергә чакыра.


**Бүген республикада 326 мең инвалид кеше исәпләнә, шуның 14 меңе – балалар, 5,7 меңе – колясkada гына хәрәкәт итә алган инвалидлар, 9 меңе – сукыр яки бик начар күрүчеләр, 5 меңе – ишетү органы зәгыйфь булучылар.**



## 9 нчы декабрь – Бөтендөнья ришвәтчелеккә каршы көрәш көне

Хезмәт вазыйфасыннан файдалану, ришвәт бирү, алу, вәкаләтләрдән явыз ният белән файдалану, кызыктырып сатып алу яки физик затның үз файдасы өчен законга каршы килеп акча, кыйммәтле һәм башка мөлкәтләрне кулга төшерү яки өченче затларны да моңа җәлеп итүе, шулай ук юридик һәм башка затлар исеменнән законга каршы булган шундый башка гамәлләр кылу. Әгәр кеше матди яки матди булмаган файда алу максатларында үзенең яки башка кешенең вазыйфаи торышыннан законсыз рәвештә файдалануда катнаша икән – ул ришвәтчелеккә каршы система өлешен тәшкил итә.

Көнкүреш мәсьләләрен хәл иткәндә вактөяк ришвәт бирү күпчелек кешеләр өчен гадәти хәл. Ришвәт тәкъдим иткән яки биргән кеше – бернинди закон да бозмый – бары тик аны алучы гына гаепле, дигән фикер яши. Әмма РФ ҖК ришвәт бирүчеләргә карата да, ришвәт алучыларга карата да җәза бирүне карый. Менә шуның өчен туганлык, танышбелешкә бәйле хезмәт торышыннан файдалану, файда алу өчен нинди дә булса эш кылу– ришвәтчелекне үз эченә ала.




Шул уңайдан мәктәптә урта сыйныфларда «Ришвәтчелекне танып белергә кирәк", "Балачактан ук коррупциясез» дигән темага класс сәгатьләре үткәрелде һәм рәсем бәйгесе оештырылды.




**Рәзилә Абдрахманова**

.

## 9 нчы декабрь— Ватан Геройлары көне

**Бу бәйрәмнең тарихы 18 гасырга барып тоташа. 1879 нчы елның 9 нчы декабрендә императрица Екатерина II Святой Георгий Победоносец орденын булдыра.**



Дүрт дәрәҗәдә булган орден белән сугышларда аеруча зур батырлык күрсәткән хәрби җитәкчеләр, солдатлар бүләкләнә. Орденның дүрт дәрәҗәсенә бары тик дүрт кешенең генә лаек булуы билгеле. Алар арасында бөек полководецлар М. Кутузов, М. Барклай-де-Толлий да бар. 1917 нче елга кадәр Россиядә Георгий кавалерлары көне билгеләп үтелә. Октябрь революциясеннән соң ордены да, бәйрәме дә гамәлдән чыгарыла инде. Бары тик 2000 нче елда гына орденга югары хәрби бүләк статусы кайтарыла.

Ә 2007 нче елда Ватан Геройлары көнен билгеләп үтү турында карар кабул ителә.

Бөек Ватан сугышы елларында 11,5 мең кеше Советлар Союзы Геройлары исеменә лаек булалар. Алар арасында безнең якташларыбыз да бар: Масгутов Минехан Масгутович, Кузнецов Анатолий Иванович, Козлов Николай Андреевич, Сергеев Михаил Егорович, Синдряков Николай Кузьмич, Михеев Павел Егорович.

**Һәр чорның үз геройлары бар. Әмма Ватанны саклап батырлык күрсәткән каһарманнарны безнең халык аеруча хөрмәт итә, онытмый.**

# Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына уку - укыту эшләре буенча директор урынбасары Хәйруллина Лилия Йосыф кызы җавап бирә.**

- Лилия Йосыфовна, ни өчен сез укытучы һөнәрен сайладыгыз?

- Укытучы һөнәренә мәхәббәтне остазым - рус теле укытучысы Тәнзилә апа Галимова уятты. Ул озак еллар буе үз эшенә тугры калган кеше. Аның тарафыннан бирелгән төпле белем миңа Казан дәүләт педагогика университетына укырга керергә мөмкинлек бирде. Укуымны уңышлы гына тәмамлагач, мин туган якларыма әйләнеп кайттым. Һәм менә инде 21 ел дәвамында балаларны укытам.

**- Укытучылар бик еш кәгазь эше күплеккә зарлана. Электрон технологияләр кертелгәч, укытучының эше җиңеләйдеме?**

- Җиңеләйде дип инде... Эшебездә компьютерлар куллануның бераз уңай яклары бар. Әйтик, минем өчен электрон журнал бик җайлы. Кәгазь журналдагы кебек нинди дә булса хата ясаудан куркып тормыйсың. Ә болай барысы да элеккечә инде – бөтен көчеңне укучыларыңны белемле итүгә куясың, аларның уңышларын күреп сөенәсең, уңышсызлыклары булса – борчыласың. Шөкер, хәзер хезмәтебез катлаулы гына түгел, мактаулы да.

**- Лилия Йосыфовна, беренче эш көнегез ничек үтте?**

- Беренче сентябрь көнне мин бик нык дулкынландым, алдагы төнне юньләп йоклый да алмадым. Иң курыкканым: яшь укытучы булганга, балалар миңа килмәс, ата-аналар ышанмаслар төсле тоелды. Әмма кулларына аллы-гөлле чәчәкләр тотып, укучыларым килде. Аллага шөкер, көнем уңышлы гына үтте.

**- Ничек уйлыйсыз, укытучы һәр балага да тигез карый аламы?** – Әйе, тәртибе, статусы ягыннан карый ала. Ә менә укытуга килгәндә, юк. Чөнки һәрбер бала – үзе бер дөнья. Аларның үзенчәлекләрен, холык-ларын тоеп, аңлап эш иткәндә генә уңай нәтиҗәләргә ирешеп була. Кемгәдер йомшак кына дәшәсең, ә кемгәдер катырак дәшкәч кенә кушканны эшли башлый. Аннан шунысы да бар: кайбер бала инде ярыйсы гына укый-яза белә, ә кемдер өйрәнеп кенә маташа. Шуларны истә тотып, һәрбер балага укыту эшен төрлечә оештырырга туры килә. Укучыларым белән киләчәктә дә уртак тел табып эшләрмен дип ышанам.

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**




## 12 декабрь – Россия Федерациясе Конституциясе көне

**1993 нче елның 12 нче декабрендә кабул ителгән Төп закон кешене, аның гражданлык хокукларын һәм демократик ирекләрен иң зур хәзинә дип игълан итте. Конституция Россиянең, социаль дәүләт буларак, федератив корылышы нигезләрен законнар белән ныгытты, аның прогрессив үсешенең хокукый нигезен булдырды, җәмгыять үсешенең яңа сәхифәсен ачты, граждannar арасында татулыкны һәм үзара аңлашуны саклап калу өчен ныклы терәк булды. Узган еллар дәвамында дәүләт хакимиятенең какшамас демократия нигезләрен гарантияли торган тотрыклы конституция системасы барлыкка килде.**

РФ Дәүләт Думасы туган илебезнең рухи яңарыш стратегиясен һәм халыкара абруен үстерүне дәвам итәр, модернизацияне, законлылык һәм хокук тәртибен алга таба ныгытуны тәэмин итәр, россиялеләр алдындагы йөкләмәләрен һичшиксез үтәр, дип ышанабыз. Нурлатлылар Россия халыкларының бердәм гаиләсендә уртак уй-фикерләр һәм мәнфәгатьләр белән яши, демократик үзгәрешләр һәм ирешкән казанышлар белән горурлана.



Илебезнең иминлеге һәм алга таба үсеше һәр гражданның тырыш һәм нәтиҗәле хезмәтенә, һәр төбәкнең уңышына бәйле. Бу уңайдан өлкән сыйныфларда «Законнар кайда туалар?» дигән ачык тәрбия сәгатьләре булды.

# 19 декабря – Международный день помощи бедным

Ежегодно 19 декабря мировое сообщество отмечает Международный день помощи бедным, установленный ООН в 1995 году. Организация Объединенных Наций рассматривает бедность как «состояние длительного вынужденного отсутствия необходимых ресурсов для обеспечения удовлетворительного образа жизни». По данным международных экспертов, на конец 20 века около четверти всего населения планеты, то есть полтора миллиарда человек, влачило нищенское существование. А проведенные исследования также показали, что в период с 1999 по 2007 года от нищеты умерло более 300 миллионов человек. Стоит отметить, что даже две мировые войны в общей сложности не унесли столько человеческих жизней. В связи с этим ООН принято несколько программ, ставящих своей целью искоренение нищеты.

Несмотря на то, что мировая экономика сегодня развивается стремительными темпами, и все больше людей могут похвастаться высоким уровнем жизни, нищета по-прежнему является одной из ключевых проблем человечества. Ведь бедность означает не только недостаток денег, но и отсутствие достойной работы, удобного жилья, доступа к хорошему образованию и здравоохранению. Во многих странах мира традиционно помощь бедным, наряду с государственными и международными программами, осуществляют различные религиозные и благотворительные общественные организации, а также частные меценаты.

***Агач хәтта үзен кисеп торган кешегә дә күләгә бирә***



## Җилкәннәр җилдә сынала

**Укуга өндәү**

“Китап – белем чишмәсе”-дип  
Әйтүләре хак икән,  
Китапны кулыма алсам,  
Мин онытылып китәм.  
Телсез мөгаллим кебек, ул  
Бер сихри көчкә ия:  
Беләм элек ни булганын,  
Ни көткәнен иртәгә,  
Тәрбияли, белем бирә,  
Күңелләрне күтәрә.  
Тик дөрес тәрбия, гыйлем  
Укучыларга илтәлә.

***Әһлиуллина Гөлназ***

## Олимпиада — тырыш һәм сәләтлеләр бәйгесе

**Ниһаять, олимпиадаларның район турында җиңүчеләр дә билгеле булды:** инглиз теле буенча Шарапова Ләйсән белән Шакурова Алсу, тормыш иминлеге нигезләре фәненнән Хәйруллин Булат, Сафиуллин Хәлил призлы урынга ия булса, рус теле буенча Әһлиуллин Аяз, биологиядән Вәгыйзова Ләйсән, җәмгыять белеменнән Гайсина Гөлшат призлы урынга ия булдылар. Ә инде иң-иң бәхетлеләр—Хәйруллин Булат географиядән, Шарапова Ләйсән белән Гафурова Алия татар теленнән ҖИҢҮ яуладылар. II яртыеллыкта алар республикага район данын якларга барачаклар!

**Укучыларыгыз белән котлыйбыз, дуслар! Алдагы бәйгеләрдә дә сынатмассыз дип ышанып калабыз! Укучылар сезгә!**



# Көлке хикмәте

*****

Укытучы эштән кайтып килгәндә, подъезд төбендә бер бандит ташлана:

- Отдай часы! - ди укытучыга.

Укытучы коты очып, ялвара:

- Часы не отдам!!! Бери классное руководство!!!

****

Әтисе улына:

- Улым, син үсеп җиттең инде, кем булырга уйлыйсың?

- Әти, мин Кыш бабай булырмын ахры!

- Нишләп? !

- Нишләп дип, чөнки ул Яңа елга кадәр бер атна һәм Яңа елдан соң бер атна гына эшли.

*****

Урыс теле дәресендә:

- Рустем, телефон звОнит или звонИт???

- Белмим, Марья Ивановна, у меня шалтырата!

*****

Бер хәлсез генә бөкре кеше бу-ла. Урамнан барганда, бер малай аның җилкәсенә таш белән бәрә. Бөкре, малайны чакырып ала да, бераз акча бирeп::

- Ай, акыллым, бик тәз атасың икән, - ди. Аннан, урамнан узып баручы таза кешегә күрсәтеп:

-- Бар әле, әнә шул кешегә дә бәр, ул бай, күбрәк бирер, - ди.

Малай, ышанып, теге кешегә дә бәрә. Шул кеше малайны тотып ала да бик үткәреп яңаклый.

## Результат анкетирования обучающихся «Что ты знаешь о СПИДе?»

**Участвовали 32 ученика (8 – 11классы)**

**Целью данной анкеты является получение информации относительно знаний о профилактике ВИЧ — инфекции и СПИДа**

| Вопрос | да | нет | Не знаю |
|---|---|---|---|
| 1. Поражается ли при СПИДе иммунная (защитная) система организма человека? | | | |
| 2. Возможно ли вылечить больного СПИДом? | | | |
| 3. Может ли человек заразиться при прикосновении к больному СПИДом? | | | |
| 4. Может ли вирус иммунодефицита человека (ВИЧ) передаваться через общую расческу, зубную щетку? | | | |
| 5. Можете ли вы заразиться СПИДом, пользуясь общим стаканом или ложкой с ВИЧ-инфицированным? | | | |
| 6. Можете ли вы заразиться ВИЧ в бассейне? | | | |
| 7. Возможно ли заражение, если вы обнимаетесь с больным человеком? | | | |
| 8. Если сегодня результат вашего анализа отрицательный, можете ли вы на 100% быть уверены, что у вас нет ВИЧ? | | | |
| 9. Передается ли СПИД половым путем? | | | |
| 10. Как вы думаете, возможно ли заразиться СПИДом:<br>- через укусы насекомых?<br>- при переливании крови?<br>- при поцелуях? | | | |
| 11. Знаете ли вы, где можно пройти анонимное обследование на СПИД? | | | |
| 12. Увеличивается ли риск заражения при беспорядочных половых связях? | | | |
| 13. Относятся ли наркоманы к «группе риска»? | | | |
| 14. Предохраняют ли презервативы от заражения СПИДом? | | | |



## Хуш киләсең, Яңа ел!

**ИГЪТИБАР!**
**БЕЛДЕРҮ**
**28 нче декабрь көнне мәктәбебездә укучылар өчен**
**Яңа ел бәйрәмнәре булачак.**
**Барыгызны да Яңа ел бәйрәмендә**

Кызганыч, ветераннарыбызның сафлары елдан-ел сирәгәя. Декабрь аенда Зирекле авылында яшәүче Миңнеголов Әделхан Ибраһим улы белән хушлаштык. Узган ел гына очрашуга барган идек әле авылдагы соңгы сугыш солдаты янына. Ветеран яшь буынга сүз белән дә, шәхси тормыш үрнәге белән дә өлге булды. Авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын Бөек Җиңү солдатының!

## КОТЛЫЙБЫЗ!

***Кадерле укучылар, укытучылар, техник хезмәткәрләр һәм әти-әниләр!***

**Сезнең барыгызны да Яңа ел белән котлыйбыз!**

**Сәламәтлек һәм бәхет-шатлык белән тулы көннәр, байлык һәм күңел тынычлыгы сезне читләтеп үтмәсен. Хыялларыгызның һәр барчасы тормышка ашсын, бәхетләрегез ташып торсын! Сезгә укуыгызда һәм эшегездә уңышлар телибез!**

**Сәламәтлек бирсен Яңа ел,**
**Бәхет булып үтсен түрләргә.**
**Тигез көннәр, озын гомер бирсен,**
**Менәр өчен биек үрләргә!**



## ЯҢА ЕЛ КОТЛЫ БУЛСЫН!

ҺӘРКАЙСЫБЫЗ ТЕЛӘК ТЕЛИ
Алдагы Яңа елда:
“Җанга шатлык тулсын!”- диеп
Башлап җибәрә **Илнар.**
“Еллар имин булсын!” – диеп
Кушыла **әти-әниләр.**
**Виктория** өстәп әйтә:
“Чынга ашсын теләкләр!”
“Уңнан булсын юлларыбыз!” –
Диеп тели **Алинә.**
“Яңа ел елмаеп килсен!” –
Ди сөенеп **Әдилә.**
“Яшәмик, дуслар, моңаеп!” –
Дип хуплый аны **Рәмис.**

“Сәламәтлек юлдаш булсын!” –
Дип саулык тели **Әлфис.**
“Табыннар тулып торсын!”, – дип
Өстәп җибәрә **Гайшә.**
“Яңа ел котлы булсын!” – дип
Кушыла аңа **Гөлшат.**
“Әниләрнең фатихасы
Саклап йөртсен!”- ди **Аяз.**
Бәрәкәтле байлык тели
Һәркайсыбызга **Илназ.**
“Ходайдан гомер сорыйк!”- дип
Тәкъдим итте **Рәзилә.**
“Һәм күңел тынычлыгы да!”-
Дип өстәде **Рузилә.**

**Сыйныф җитәкчесе**нең дә
Бик изге теләкләре:
“Тормышта терәк булырлык
Чын дуслар кирәк әле!”
Хәтта кар да җир өстенә
Аклык теләп ява ул.
Теләкләрне кабул итеп,
Имин үтсен Яңа ел!

**7 нче сыйныф укучылары**
**Һәм сыйныф җитәкчеләре**
**Гөлүсә Әһлиуллина**

Декабрь аенда туучы кадерле укытучыларыбыз һәм техник хезмәткәрләребез: **Хәйруллина Лилия Йосыф кызы, Гыйрфанова Ралия Наил кызы, Әһлиуллина Гөлүсә Дамир кызы, Хисматов Рамил Гариф улы!**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!

Декабрь аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Щербаков Тимур, Мишин Ислам, Ахметова Назиля, Гумерова Ләйсән!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

## Туган көн

Әллә елга бер килгәнгә,
Туган көн – искиткеч көн:
Бар да сиңа елмаялар,
Үзең дә гел бие, көл.

Һичкем сине ачуланмый,
“Чуалып йөрмә!” – димиләр...
Бүләкләр ишелеп килә,
Изге теләк телиләр.

Елның һәрбер көне шулай
Тик сөенеч китерсен.
Һәр көн яңа көн туа бит,
Шуңа шөкер итсәң син,
Әйбәт гомер итәрсең!

***Әһлиуллина Гөлназ***




**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хайбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Юнусова Виктория, Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова А.лсинә, Ахметова Нәзилә.